*Муниципаль тур*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА

# БИРЕМНӘРЕ

(2025-2026 нчы уку елы)

**8 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 62**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Ирен ассимиляциясе күзәтелгән сүз кергән мәкальне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) Кая барсаң да, бер кояш.
   ә) Кояш барда, йолдыз күренми.
   б) Кояш та тапсыз булмый.
   в) Кызарып чыккан кояшны болыт каплый.
2. Нокталар урынына **ә** хәрефе языла торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) мәшәк..ть
   ә) мәгълүм..ть
   б) һәмм..
   в) гыйб..рәт
3. Фразеологизмның мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
   ***бака туе ясау***
   а) бик күп кеше җыелган урын
   ә) кунаклар аз булган туй
   б) бер-берсен тыңламыйча, кычкырып сөйләшү
   в) сугышу, кычкырышу
4. Ономастикага туры килә торган аңлатманы билгеләгез. **(2 балл)**
   а) сүзләрне өйрәнә
   ә) ялгызлык исемнәрен өйрәнә
   б) сүзләрнең килеп чыгышын өйрәнә
   в) сүзләрнең тарихын өйрәнә
5. Мәгънәдәш сүзләр ярдәмендә ясалган парлы сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) берән-сәрән
   ә) аз-маз
   б) эреле-ваклы
   в) иелә-бөгелә
6. Кимлек дәрәҗәсендә кулланылмый торган сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) салкын
   ә) җылы
   б) әче
   в) табигый

7. Шарт фигыль кулланылган мәкальне билгеләгез. **(2 балл)**

а) Ашыккан су диңгезгә җитмәс.
ә) Тау булгач, чокыры булыр.
б) Уйнап сөйләсәң дә, уйлап сөйлә.
в) Абынмас җирдә абынма, абруең төшәр.

8. Ымлыкны билгеләгез. **(2 балл)**

а) хуш
ә) әлбәттә
б) ягъни
в) түгел

9. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез. **(2 балл)**

*Ишегалдыннан аккан* ***суның*** *кадере юк.* (Мәкаль)

а) ия
ә) хәбәр
б) аергыч
в) тәмамлык

10. Инкяр җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**

а) Күл булса, бака борынын тыгар. (Мәкаль)
ә) Яхшы суны ерак түкмиләр. (Мәкаль)
б) Су чокыр җиргә җыелыр. (Мәкаль)
в) Болганган су тирән күренер. (Мәкаль)

## II. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(6 балл)**

Яңгырау тартыкларның җидесе _____________ тартыклар дип атала. Сүздәге авазларны ишетелгәнчә язу – _____________ принцип. Билгеле бер төбәктә яшәүчеләр генә куллана торган сүзләр – _____________ сүзләр. Форма ясагыч кушымчалар нигез эченә _____________. Сан ачыклаган исем _____________ дип атала. Тезүле бәйләнешне белдерә торган чаралар – _____________ һәм тезүче теркәгечләр.

## III. Башыгызны эшләтегез.

Парлы сүзләрнең беренче компонентларын уйлап языгыз. **(4 балл)**

| | |
|---|---|
| ________-зар | ________-шәфкать |
| ________-шәрәм | ________-каза |

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(6 балл)**

Всё небо в тучах. ________________________________________________

Часто идут дожди. ______________________________________________

Дует злой ветер. _______________________________________________

Люди надели на себя тёплые вещи.____________________________________

_________________________________________________________________

С огородов и полей убрали последние овощи. _________________________

________________________________________________________________

2. Шигырьне укыгыз һәм биремнәрне эшләгез.

СӘГАТЬ

Тау артыннан кояш чыгып, таң аттыра,
Күккә менеп, безнең эшне карап тора.
Менә сәгать, барчабызны эшкә чакырып,
«Тик-тик» үткән секундларны санап тора.
Сәгать әйтә: – Әйдә, иптәш, әйдә,
Заман белән бергә атла, бергә өйрән.
Минутларның, секундларның кадерен бел, – ди, –
Укуың калса, үкенерсең вакыт үткәч.

*(Гамил Афзал)*

2.1. Сингармонизм законының рәт гармониясенә буйсынмаган сүзләрне күчереп языгыз. **(2 балл)** ________________________________________

2.2. Саңгыраулыкта охшашлану күзәтелгән сүзләрне күчереп языгыз. **(3 балл)** _____________________________________________________

2.3. Басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләрнең санын языгыз. **(2 балл)** ____

2.4. Гарәп-фарсы алынмаларын күчереп языгыз. **(3 балл)** __________________
________________________________________________________________

2.5. Затланышсыз фигыльләрне күчереп языгыз. **(3 балл)** _________________
________________________________________________________________

2.6. Эндәш сүзне күчереп языгыз. **(1 балл)** ________________________________

3. **«Буш вакытымны файдалы үткәрәм»** дигән темага 8-10 җөмләдән торган инша языгыз. **(12 балл)**

________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________